**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле авылында 2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**16 декабрь 2022 ел** **№5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Олы Кариле авылында гражданнарның җыены карар итте**:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-поселок эчендәге вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (вак таш салынган чокырларны ямау, таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- обелискны ремонтлау, шул исәптән Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар исемлеген яңарту, Җиңү Орденын яңарту (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Беларус 82,1 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу);

-янгын депосы һәм автоцистернаны тоту (ягулык-майлау материаллары, АЦ-40 өчен запас частьләр сатып алу (131), килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Гарифуллин